
# «Чык тамчысы»

**МАДОУ**

**Детский сад №49**

**«Росинка»**

***Март, 2022 ел***







Жылы кояш нурларына төренеп, йөгерек гөрләвекләре белән йөгереп язның беренче ае — март та килеп житте. Барыбызга да билгеле әлеге айның иң матур иң олы бәйрәме — 8 март — Халыкара хатын-кызлар көне. Хөрмәтле гүзәл затлар! Табигатнең суыктан жылылык чорына омтылган мизгеленә туры килгән бәйрәмегез һәрвакыт жылы матур истәлекләр генә калдырсын.

Яз ае безнең бакчабызда көтеп алынган ел фасылларының берсе. Чөнки бакчабызыда зарыгып көткән бәйрәмнәребезнең берсе “әнилэр бәйрәме”башланды! Бакчабыз балаларның яңгырап торган шат жырларына, матур шигырьләренә, күңелле биюләренә күмелде. Балалар да әлеге бәйрәмгә бик теләп әзерләнгәннәр. Алар залыбызда утырган кунакларга, әти-әниләргә үзләренең сәләтләрен, уңганлыкларын, осталыкларын күрсәттеләр, матур жырлары, биюләре белән бәйрәм иртәләрен тагын да ямьләндереп жибәрделәр.


8
марта




8
марта





# *А у нас Масленица!*

Май чабу бәйрәме — бик борынгы заманнан сакланып килгән, көтеп алынган иң күңелле бәйрәмнәрнең берсе.Ул җиде көн дәвам итә. Борынгы бабаларыбыз аны төрле йолалар белән үреп үткәргәннәр. Бу көннәрдә кешеләр күңел ачалар, кунакка йөрешәләр һәм коймак ашыйлар. Быел ул 28 февральдән 6 мартка кадәр дәвам итте. Коймак атнасы – язны каршылауга багышланган тантаналы вакыйга. Олы уразага керер алдыннан, халык кыш белән саубуллаша, язгы җылы көннәргә шатлана, сөенә.
Коймаксыз Май чабу булмый.
Коймак — кояшның туганы.
Кайда коймак — шунда без!
Иң салкын канлы кеше дә кайнар коймак ярата.
Коймаксыз Май чабу — тортсыз туган көн кебек.
Май чабу килә, коймак белән бал алып килә! дигән әйтемнәр яши.
Халыкта, әгәр Май чабу атнасын коймаклар пешереп, җырлар-биюләр, күңелле уеннар белән үткәрәсең икән, йортыңа һичшиксез бәхет керәчәк, дигән ышану бар.

В начале марта в нашем детском саду прошёл весёлый праздник «Масленица»
Масленица – это озорное прощание с зимой и встреча весны, несущее оживление природе и солнечное тепло, поэтому ведущие праздника загадывали детям загадки про зиму, весну, вспоминали русские народные пословицы и играли веселые игры. Символ Масленицы - чучело - сожгли все вместе на улице.
Но праздник на этом не закончился: детей ждали блины!











# *«День цветных бантиков»-«Төсле тасмалар көне!»*

В нашем детском саду традиционно прошел праздник "День цветных бантиков". Необыкновенность такого праздника заключается в том, что в этот день все дети и всё вокруг было украшено бантиками. Бантами украшали одежду, прически или привязывали на запястье как браслет. Больше всех к этому празднику готовились наши родители, мы им очень благодарны. Количеством и красотой бантиков удивляли не только девочки, но и мальчики. Всюду ощущалась атмосфера праздника. Банты были разных форм, цветов, размеров. Много задора, улыбок, положительных эмоций, игр, веселых конкурсов получили дети на этом празднике. А это так важно для эмоционально-психологического благополучия ребенка. "День цветных бантиков" в детском саду подарил веселый настрой не только воспитанникам, но и сотрудникам детского сада.










# Без булдырабаз!!!

Бакчабыз хезмәткәрләре, балалар бакчасында уздырылган чаралар, конкурслардан тыш шәһәр, республика, регион күләм чараларда актив катнашалар. Бакчабызда мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче Хуснутдинов Азат "Сөйкемле бала", "Мин- татар малае", "Без-Тукай Варислары" бәйгеләрендә бик теләп катнаша. Уңган, булган, тапкыр егеткә уңышлар телибез!

Бакчабызның 3нче төркемгә йөрүче Даулетов Алмаз Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәдә "Яшәү мәгънәсе - яхшы эз калдыруда" дип исемләнгән очрашуында әдәби- музыкаль чыгыш ясады. Алмазның чыгышы очрашуны тагын да ямләндереп җибәрде. Афәрин Алмаз!

Бакчабызда шундый сәләтле балалар булганга тәрбиячеләргә һәм эти-әниләргә зур рәхмәтебезне белдерәбез! Ә малайларыбызга киләчәктә яңа үрләр яулавын, конкурсларда алдынгы урыннарга ирешүен теләп калабыз!








## Котлыйбыз!!!

1.03 Вавилина Алена Викторовна

8.03 Яруллина Алсу Рафиковна

15.03 Семененко Евдакия Петровна

Сезгә иң изге, якты теләкләребезне юллыйбыз. Сәламәтлек, күңел тынычлыгы, кайгы-хәсрәтсез мул тормыш, балалар шатлыгы телибез. Кирәк һәм терәк булып, хөрмәттә яшәгез!!!

Тагын бер ел өстәлсә дә сезгә,
Ул ел сезне тагы да яшәртсен.
Нурын сибеп көләч йөзләрегезгә
Гел шат итеп кенә яшәтсен.
Ташламасын сезне беркайчан да
Бәхет белән тулы елмаю.
Урап үтсен сезне кайгы-хәсрәт,
Ә йөзегездә булсын куану!

Газета 49 нчы балалар бакчасының 9 нче төркем тарафыннан чыгарылды.
**Тәрбияче-Садыкова Венера Эльвард кызы**

Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан "Заман" уку һәм аралашу үзәгендә түгәрәк өстәл узды. Әңгәмә барышында Ислам дине кайчан һәм ничек кабул ителеүе, аның әһәмияте турында сөйләштек. Иң бөек дин белгечләренең берсе, милли тарихыбызны һәм матбугатыбызны үстерүдә гаять зур хезмәт күрсәткән, бөтен Ислам дөньясында танылган галим - Ризаэтдин Фәхретдин хакында фикер алыштык.Үзәк мөдире Ольга Агафонова үз чиратында, безне аның китаплары белән таныштырды, укырга тәкъдим итте.

